РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
БУИНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
ГЛАВА РУНГИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЫРЫҢГЫ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

«15» ноябрь 2021 ел № 2

Ырынгы авылы

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының «Буа шәһәре» муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә «Ырынгы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге чикләрен үзгәртү мәсьәләсе буенча гавами (ачык) тыңлаулар үткәрү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга таянып, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советының 2021 елның 12 ноябрендәге 3-20 нгомерлы «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы муниципаль берәмлекләре чикләрен үзгәртү турында» карары нигезендә, Ырынгы авыл җирлегендә яшәүчеләрнең гавами (ачык) тыңлаулар үткәрү юлы белән «Ырынгы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге чикләре турындагы проект буенча фикер алышуда катнашу хокукларын үтәү максатларында

КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы «Буа шәһәре» муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә «Ырынгы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең чикләрен үзгәртү мәсьәләсе буенча гавами (ачык) тыңлаулар үткәрүне Татарстан Республикасы, Буа районы, Ырынгы авылы, Совет ур., 6 йорт адресы буенча Ырынгы авыл җирлегенең Ырынгы авыл мәдәният йорты бинасында 2021 елның 10 декабренә 14.00 сәгатькә билгеләргә.

2. Гавами (ачык) тыңлауларда фикер алышына торган мәсьәләләр буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр 2021 елның 09 декабренә кадәр түбәндәге адрес буенча кабул ителә: Ырынгы авылы, Совет ур., 6 йорт, Ырынгы авыл җирлеге Башкарма комитеты, телефон +7(84374) 5-26-35.

3. Әлеге карар Ырынгы авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерелергә тиеш:
- ТР, Буа районы, Ырынгы авылы, Совет урамы, 8А йорт;
- ТР, Буа районы, Чурак авылы, Үзәк урам, 12В йорт.


4. Әлеге карар Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча рәсми басылып чыккан көннән законлы көченә керә, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://buinsk.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырылырга тиеш.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп тотуны үземә йөклим.

Татарстан Республикасы Буа муниципаль
районы Ырынгы авыл
җирлеге башлыгы Р.И. Гордеев

Приложение
к постановлению главы
Рунгинского сельского поселения
Буинского муниципального района РТ
от « 15 » ноября 2021 г. № 2

Муниципаль берәмлекләр чикләренең
үзгәрешләр исәпкә алынган карта-схемасы




Шартлы билгеләр

- Татарстан Республикасы чиге
- Буа муниципаль районы чиге
- Муниципаль берәмлекләр чикләре
- А-Б - Түбән Наратбаш авыл җирлеге һәм «Буа шәһәре» муниципаль берәмлегенең чиктәш чиге
- В-Г - Ырынгы авыл җирлеге һәм «Буа шәһәре» муниципаль берәмлегенең чиктәш чиге
- Г-Д - Татар Буасы авыл җирлеге һәм «Буа шәһәре» муниципаль берәмлегенең чиктәш чиге
- Җирлекләрнең административ үзәкләре
- Торак пунктлар
- Буа муниципаль районының Түбән Наратбаш авыл җирлеге территориясе составына керүче Буа муниципаль районының «Буа шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясе
- Буа муниципаль районының «Буа шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясе составына керүче Буа муниципаль районының Ырынгы авыл җирлеге территориясе
- Буа муниципаль районының «Буа шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясе составына керүче Буа муниципаль районының Татар Буасы авыл җирлеге территориясе
- Буа муниципаль районының «Буа шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясе составына керүче Буа муниципаль районының Түбән Наратбаш авыл җирлеге территориясе